**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 17 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, 90 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, мобилизованныйларнын гаилэ эгъзалэреннэн тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Чураш торак пунктындагы урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
2) Чураш торак пунктындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;
3) Чураш авылы зираты өчен чапкыч сатып алу;
4) район газетасында некрологлар һәм юбилярларны котлаулар бастыру;
5) Чураш торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (бетон каркаслар сатып алу һәм урнаштыру,) ;
6) Чураш авылы мәдәният йорты өчен музыка аппаратурасы сатып алу;

3. Әлеге карарны Карашай-Саклау авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева